| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

18.11.2016 Казан ш. № 6-180/тп

«Генерацияләү компаниясе» ачык акционерлык җәмгыятенең Түбән Кама җылылык челтәрләре филиалына тоташтырыла торган җылылык йөкләнеше куәте берәмлеге исәбеннән җылылык белән тәэмин итү системасына тоташтырган өчен (технологик тоташтыруга) 2017 елга түләүләрне билгеләү турында

«Җылылык белән тәэмин итү турында» 2010 елның 27 июлендәге 190 - ФЗ санлы Федераль законга, «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә бәяләр хасил итү турында» 2012 елның 22 октябрендәге 1075 санлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карарына, «Җылылык белән тәэмин итү системаларына тоташтыру тәртибе һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайсыбер актларына үзгәрешләр кертү турында» 2012 елның 16 апрелендәге 307 санлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карарына, «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә җайга салынучы бәяләрне (тарифларны) исәпләп чыгару буенча методик күрсәтмәләрне раслау турында» тарифлар буенча Федераль хезмәтнең 2013 елның 13 июнендәге 760-э санлы боерыгына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 санлы карары белән расланган Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты турындагы нигезләмәгә туры китереп, Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Генерацияләү компаниясе» ачык акционерлык җәмгыятенең Түбән Кама җылылык челтәрләре филиалына тоташтырыла торган җылылык йөкләнеше куәте берәмлеге исәбеннән, әгәр мөрәҗәгать итүче объектының тоташтырыла торган җылылык йөкләнеше 0,1 Гкал/сәгатьтән артыграк булып һәм ул 1,5 Гкал/ сәгатьтән артып китмәгән очракта, җылылык белән тәэмин итү системасына тоташтырган өчен түләүләрне әлеге карарның 1 кушымтасы нигезендә билгеләргә.

2. «Генерацияләү компаниясе» ачык акционерлык җәмгыятенең Түбән Кама җылылык челтәрләре филиалына тоташтырыла торган җылылык йөкләнеше куәте берәмлеге исәбеннән, әгәр мөрәҗәгать итүче объектының тоташтырыла торган

җылылык йөкләнеше, тоташтыруның техник мөмкинлекләре булганда, 1,5 Гкал/сәгатьтән артып киткән очракта, җылылык белән тәэмин итү системасына тоташтырган өчен түләүләрне әлеге карарның 2 кушымтасы нигезендә билгеләргә.

3. Әлеге карарның 1 һәм 2 пунктларында билгеләнгән түләүләр, 2017 елның 1 гыйнварыннан 2017 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән соң ун көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы тарифлар
буенча Дәүләт комитеты рәисе М.Р.Зарипов

Татарстан Республикасының
тарифлар буенча дәүләт комитетының
18.11.2016 № 6-180/тп
карарына кушымта 1

«Генерацияләү компаниясе» ачык акционерлык җәмгыятенең Түбән Кама җылылык челтәрләре филиалына тоташтырыла торган җылылык йөкләнеше куәте берәмлеге исәбеннән, әгәр мөрәҗәгать итүче объектының тоташтырыла торган җылылык йөкләнеше 0,1 Гкал/сәгатьтән артыграк булып һәм ул 1,5 Гкал/ сәгатьтән артып китмәгән очракта, җылылык белән тәэмин итү системасына тоташтырган өчен 2017 елга түләүләр

мең сум/Гкал/сәг.

| № п/п | Исеме | Билгесе |
|---|---|---|
| 1 | Мөрәҗәгать итүчеләр объектларын тоташтыру буенча чаралар үткәрүгә чыгымнар(П1) | 10,350 |
| 2 | Гамәлдәге җылылык челтәрләреннән яисә җылылык энергиясе чыганакларыннан алып, мөрәҗәгать итүчеләр объектларының тоташтыру нокталарына кадәр, тоташтырыла торган җылылык йөкләнеше 0,1 Гкал/сәгатьтән артыграк булып һәм ул 1,5 Гкал/ сәгатьтән артып китмәгән очракта, җылылык челтәрләрен төзүгә(үзгәртеп коруга) (җылылык пунктларын төзүдән (үзгәртеп корудан) тыш) чыгымнар (П2.1), шул исәптән: | |
| 2.1 | Җирдән өстәрәк( җир өстендә) ара катлау | |
| 2.1.1 | 50 - 250 мм | - |
| 2.1.2 | 251 - 400 мм | - |
| 2.1.3 | 401 - 550 мм | - |
| 2.1.4 | 551 - 700 мм | - |
| 2.1.5 | 701 мм һәм аннан югарырак | - |
| 2.2 | җир астында ара катлау , шул исәптән: | |
| 2.2.1 | каналлы ара катлау | |
| 2.2.1.1 | 50 - 250 мм | 1273,94 |
| 2.2.1.2 | 251 - 400 мм | - |
| 2.2.1.3 | 401 - 550 мм | - |
| 2.2.1.4 | 551 - 700 мм | - |
| 2.2.1.5 | 701 мм һәм аннан югарырак | - |
| 2.2.2 | каналсыз ара катлау | |
| 2.2.2.1 | 50 - 250 мм | - |
| 2.2.2.2 | 251 - 400 мм | - |
| 2.2.2.3 | 401 - 550 мм | - |
| 2.2.2.4 | 551 - 700 мм | - |
| 2.2.2.5 | 701 мм һәм һәм аннан югарырак | - |

| | | |
|---|---|---|
| 3 | Гамәлдәге җылылык челтәрләреннән яисә җылылык энергиясе чыганакларыннан алып, мөрәҗәгать итүчеләр объектларының тоташтыру нокталарына кадәр, тоташтырыла торган җылылык йөкләнеше 0,1 Гкал/сәгатьтән артыграк булып һәм ул 1,5 Гкал/сәгатьтән артып китмәгән очракта, җылылык пунктларын төзүгә (үзгәртеп коруга) чыгымнар (П2.2) | - |
| 4 | Табышка салым | - |

Татарстан Республикасы тарифлар буенча
Дәүләт комитеты, Тарифлар буенча карарларны
кабул итү, оештыру һәм җайга салу бүлеге

Татарстан Республикасының
тарифлар буенча дәүләт комитетының
18.11.2016 № 6-180/тп
карарына кушымта 2

«Генерацияләү компаниясе» ачык акционерлык җәмгыятенең Түбән Кама җылылык челтәрләре филиалына тоташтырыла торган җылылык йөкләнеше куәте бирәмлеге исәбеннән, тоташтыруның техник мөмкинлекләре булганда, мөрәҗәгать итүче объектының тоташтырыла торган җылылык йөкләнеше 1,5 кал/сәгатьтән артып киткән очракта, җылылык белән тәэмин итү системасына тоташтырган өчен 2017 елга түләүләр

мең сум/Гкал/сәг.

| № п/п | Исеме | Билгесе |
|---|---|---|
| 1 | Мөрәҗәгать итүчеләр объектларын тоташтыру буенча чаралар үткәрүгә чыгымнар($П_1$) | 10,350 |
| 2 | Гамәлдәге җылылык челтәрләреннән яисә җылылык энергиясе чыганакларыннан алып, мөрәҗәгать итүчеләр объектларының тоташтыру нокталарына кадәр, тоташтыруның техник мөмкинлекләре булганда, тоташтырыла торган җылылык йөкләнеше 1,5 Гкал/ сәгатьтән артып киткән очракта, җылылык челтәрләрен төзүгә(үзгәртеп коруга) (җылылык пунктларын төзүдән (үзгәртеп корудан) тыш) чыгымнар($П_{2.1}$), шул исәптән: | |
| 2.1 | җирдән өстәрәк (җир өстендә) ара катлау | |
| 2.1.1 | 50 - 250 мм | - |
| 2.1.2 | 251 - 400 мм | - |
| 2.1.3 | 401 - 550 мм | - |
| 2.1.4 | 551 - 700 мм | - |
| 2.1.5 | 701 мм һәм аннан югарырак | - |
| 2.2 | җир астында ара катлау , шул исәптән: | |
| 2.2.1 | каналлы ара катлау | |
| 2.2.1.1 | 50 - 250 мм | 1273,94 |
| 2.2.1.2 | 251 - 400 мм | - |
| 2.2.1.3 | 401 - 550 мм | - |
| 2.2.1.4 | 551 - 700 мм | - |
| 2.2.1.5 | 701 мм һәм аннан югарырак | - |
| 2.2.2 | каналсыз ара катлау | |
| 2.2.2.1 | 50 - 250 мм | - |
| 2.2.2.2 | 251 - 400 мм | - |
| 2.2.2.3 | 401 - 550 мм | - |
| 2.2.2.4 | 551 - 700 мм | - |

| | | |
|---|---|---|
| 2.2.2.5 | 701 мм һәм аннан югарырак | - |
| 3 | Гамәлдәге җылылык челтәрләреннән яисә җылылык энергиясе чыганакларыннан алып, мөрәҗәгать итүчеләр объектларының тоташтыру нокталарына кадәр, тоташтыруның техник мөмкинлекләре булганда, тоташтырыла торган җылылык йөкләнеше 1,5 Гкал/ сәгатьтән артып киткән очракта, җылылык пунктларын төзүгә (үзгәртеп коруга) чыгымнар ($П_{2.2}$) | - |
| 4 | Табышка салым | - |

Татарстан Республикасы тарифлар буенча
Дәүләт комитеты, Тарифлар буенча карарларны
кабул итү, оештыру һәм җайга салу бүлеге